ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Янгын куркынычсызлыгы турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 25 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 февралендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 2; 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 6; 2011, № 5; 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән гамәлгә ашырыла.»;

2) 2 статьяның өченче өлешендәге 9 пунктында «эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр» сүзләрен «эшчәнлекне гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяның унбишенче абзацында «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 14 статьяның өченче өлешендә «янгын куркынычсызлыгы таләпләрен» сүзләрен «янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләрен (алга таба – янгын куркынычсызлыгы таләпләре)» сүзләренә алмаштырырга;

5) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«21 статья. **Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлек**

Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлек янгын куркынычсызлыгы таләпләрен гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук янгыннарны кисәтү һәм сүндерү максатларында башкарыла. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләре исемлеге Федераль закон белән билгеләнә.»;

6) 22 статьяда:
а) икенче өлештә «һәм (яисә) янгын-техник минимумы программалары» сүзләрен «программалары, өстәмә һөнәри программалар» сүзләренә алмаштырырга;
б) өченче өлештә «янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү тәртибе, төрләре, сроклары, шулай ук өстәмә һөнәри белем бирү программалары (янгын-техник минимумы программалары) эчтәлегенә карата таләпләр» сүзләрен «янгынга каршы инструктаж программалары буенча өйрәтү тәртибе, төрләре, сроклары, шулай ук күрсәтелгән программалар эчтәлегенә карата таләпләр» сүзләренә алмаштырырга;
в) дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем алучы затларның категорияләре федераль башкарма хакимиятнең янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 11 декабрь
№ 93-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ